| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

30.07.2014 Казан ш. № 1565-р

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 03.02.2012 ел, №243-р боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә даими (срогы билгеләнмәгән) файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 03.02.2012 ел, №243-р боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә даими (срогы билгеләнмәгән) файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлектә:

“Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасында 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан регламентны бозу очракларының (нигезле шикаятьләр) булуы (мондый очраклар, шикаятьләр санының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның вазыйфаи затларының гомуми санына карата нисбәте).

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора:

Министрлыкның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы;

белгечләрнең кирәкле санда булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү өчен кирәкле бүлмәләрнең тиешле санда булуы;

Министрлыкның мәгълүмати стендларында, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, рәсми сайтында, Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы”;

2) 3 бүлектә:

бүлек атамасына “, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре” дигән сүзләрне өстәргә;

3.2 пунктның беренче абзацында “җиргә хокукларны теркәүне һәм дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү бүлегенә” дигән сүзләрне “дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлегенә” дигән сүзләргә алыштырырга;

3.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә һәм ярдәм күрсәтә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, аларны рәсмиләштерү буенча һәм дәүләт хезмәте алуга кагылышлы башка мәсьәләләр буенча.”;

бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге яңа 3.3.4$^{1}$ пунктны өстәргә:

“3.3.4$^{1}$. Мәгълүмат белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша алынган, 3.3.4 пунктта күрсәтелгән запрослар нигезендә соралган документларны (мәгълүматлар) билгеләнгән срокта тапшыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торучы документлар, мәгълүматларны яки баш тарту турында уведомлениене Министрлыкка җибәрү.”;

3.3.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.3.15. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә һәм күп функцияле үзәк аша күрсәтелми.”;

3) 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 4.4 пунктын өстәргә:

“4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән хәл ителә.”;

4) 5 бүлектә:

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.3. Шикаять почта аша, күп функцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.”;

5.4 пунктның 1 пунктчасында “запросны” дигән сүзне “мөрәҗәгатьне” дигән сүзгә алыштырырга;

бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.9 һәм 5.10 пунктларны өстәргә:

“5.9. Шикаятьләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карап тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.”;

5) №3 кушымтада “җирләрне арендалау һәм сату бүлеге” дигән сүзләрне “дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге” дигән сүзләргә алыштырырга.

6) Кушымтаны (белешмә) кушымта итеп бирелгән редакциядә бәян итәргә.

2. Бу боерыкның үтәллешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы милкендәге ир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә даими (срогы билгеләнмәгән) файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

**Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә даими (срогы билгеләнмәгән) файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны күрсәтүгә контрольлек итүче вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы**

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе начальнигы<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге начальнигы<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-89 | Artur.Galiev@tatar.ru |
| Делопроизводство һәм контрольлек бүлеге начальнигы<br>Румянцева Гөлнур Ниязи кызы | 221-40-81<br>221-40-83<br>221-40-79 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар  Кабинеты Аппараты**

Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе начальнигы Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |
| Идарә начальнигы урынбасары Аксанов Валерий Аркадьевич | 264-76-89 | Valeriy.Aksanov@tatar.ru |

**Министр** **А.К.Хамаев**